**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422650, пгт. Рыбная Слобода,
ул. Ленина, дом 48

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422650, Балык Бистәсе,
Ленин урамы, 48 нче йорт

Тел.: (84361) 22113, факс: (84361) 23012, e-mail: balyk-bistage@tatar.ru, сайт: ribnaya-sloboda.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.01.2018 Балык Бистәсе штп. № 13пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 23.09.2013 №202пи карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы белем бирү оешмаларына йөрүче балаларга социаль ярдәм күрсәтү максатларында Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тәкъдимнәрен исәпкә алып һәм «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Мәгариф турында» 2013 елның 22 июлендәге 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының 2013 елның 23 сентябрендәге 202пи номерлы карары (Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитетының 2014 елның 6 февралендәге 17 пи номерлы, 2014 елның 20 февралендәге 28 пи номерлы, 2015 елның 25 февралендәге 61 номерлы, 2015 елның 30 октябрендәге 299пи номерлы, 2016 елның 11 маендагы 68пи номерлы, 01.03.2017 № 38пи номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) белән расланган мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына йөрүче балаларга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 нче бүлек « Компенсацияне билгеләү һәм түләү тәртибе» түбәндәге эчтәлекле 2.7 пункт өстәргә:

«2.7.Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзгенең гражданның компенсация алу хокукын раслаучы белешмәләре булганда, компенсация яңа срокка гражданин мөрәҗәгатеннән башка билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация

челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

12.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Р. Хисмәтовка йөкләргә.

Җитәкче
вазифаларын башкаручы И.Р. Таҗетдинов